Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы
Урта Көшкәт авыл җирлегенең Сала-Көшкәт торак пунктында
ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

24 ноябрь 2023 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Урта Көшкәт авыл җирлегенең Сала-Көшкәт торак пунктында халык җыены Карар кабул итте:

1. «95% күләмендә ташлама билгеләнгән Бөек Ватан сугышы ветераннары, 1 төркем инвалидлар, балачактан инвалидлар, ялгыз өлкән пенсионерлар һәм өлкән яшьтәгеләр, көндезге уку формасы буенча укучы студентлар, Россия Армиясендә хезмәт итүчеләр, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, Урта Көшкәт авыл җирлегенең Сала-Көшкәт авылында яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2024 нче елда үзарасалымны 500 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- юл-урам челтәрен асфальт-бетон өслек белән норматив хәлгә китерү.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Урта Көшкәт авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә baltasi.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru).

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Урта Көшкәт авыл җирлеге башлыгы Перфилов Ю. М.